КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 968

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 ел, 16 август, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 ел, 16 август, 563 нче карары белән расланган Татарстан Республикасындагы төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «(алга таба – Идарә)» сүзләреннән соң «, шул исәптән куркынычка йөз тоткан якын килүне кулланып.» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 14.1 пункт өстәргә:

«14.1. Идарә юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне планлы һәм планнан тыш тикшерүләр турында, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары эшчәнлеге хакында, тикшерүләр нәтиҗәләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрында ачыкланган бозуларны кисәтү һәм (яки) аларның нәтиҗәләрен бетерү буенча күрелгән чаралар турында мәгълүматларны урнаштыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 17 – 25 пунктлар өстәргә:

«17. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану максатларында юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын (алга таба – төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектлары) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка йөз тоткан якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә куркынычның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү әлеге Нигезләмәгә кушымтада китерелгән критерийләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын куркыныч категорияләренең берсенә кертү, куркыныч категориясен үзгәртү Идарә башлыгы яки аның урынбасары карары белән гамәлгә ашырыла.

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектын куркыныч категорияләренең берсенә кертү турында карар булмаганда ул түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

19. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына карата планлы тикшерүләр үткәрү бирелгән куркыныч категориясенә бәйле түбәндәге вакыттан вакытка кабатлана:

гаять югары куркыныч категориясе өчен – өч елга бер тапкырдан еш түгел;

югары куркыныч категориясе өчен – өч елга бер тапкырдан еш түгел;

урта куркыныч категориясе өчен – дүрт елга бер тапкырдан еш түгел;

уртача куркыныч категориясе өчен – бишт елга бер тапкырдан еш түгел.

Түбән куркыныч категориясенә кертелгән төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелми.

20. Идарә планлы тикшерүләр үткәрелгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләрен алып бара.

Эшчәнлекләре куркыныч категориясенә кертелгән юридик затларны һәм шәхси эшмәкәрләрне аларга мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелә торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлегенә кертү Идарә башлыгы яки аның урынбасарының юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген тиешле куркыныч категорияләренә кертү турында карары белән гамәлгә ашырыла.

21. Аларга мөнәсәбәттә планлы тикшерүләр үткәрелә торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләре түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) эшчәнлекләре гаять югары, югары куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм әтисе исеме (булганда);

б) юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәве саны;

в) салым түләүченең шәхси номеры;

г) эшчәнлекләре гаять югары, югары куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның исеме яки шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны;

д) куркыныч категориясе бирү турында карар реквизитлары, куркынч категориясенә күрсәтмә, шулай ук алар нигезендә юридик затны һәм шәхси эшмәкәрне куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән мәгълүматлар.

22. Идарәнең рәсми сайтында эшчәнлекләре планлы тикшерүләр үткәрелгән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр исемлекләрендәге гаять югары, югары куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затлар турында һәм шәхси эшмәкәрләр хакында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла һәм актуальләштерелә:

а) эшчәнлекләре гаять югары, югары куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм әтисе исеме (булганда);

б) салым түләүченең индивидуаль саны;

в) эшчәнлекләре гаять югары, югары куркыныч категорияләренә кертелгән юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны;

г) куркыныч категориясе һәм юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул итү датасы.

23. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын гаять югары, югары куркыныч категорияләренә керткәндә Идарә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында әлеге объектлар турында тиешле мәгълүматны урнаштыра.

Мәгълүматны урнаштыру дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

24. Эшчәнлекләре куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән юридик зат яки шәхси эшмәкәр соравы буенча Идарә билгеләнгән тәртиптә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә алар эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүматны, шулай ук юридик зат яки шәхси эшмәкәр эшчәнлеген куркыныч категорияләренең берсенә керткәндә файдаланылган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә бирә.

25. Юридик зат яки шәхси эшмәкәр билгеләнгән тәртиптә Идарәгә төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларына элек бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында гариза бирергә хокуклы.»;

Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасындагы
төбәк дәүләт ветеринария
күзәтчелеге турындагы
нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасында төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар файдалана торган җитештерү объектларын куркыныч категорияләренә кертү критерийләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеген (алга таба – төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге) гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер куркыныч категориясенә кертү мәҗбүри таләпләрне мөмкин булган үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре авырлыгы критерийләре нигезендә (әлеге Критерийләрнең II бүлеге) һәм мәҗбүри таләпләрне мөмкин булган үтәмәү критерийләрен (әлеге Критерийләрнең III бүлеге) исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## II. Мәҗбүри таләпләрне мөмкин булган үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре критерийләре

2. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын куркыныч категорияләренә керткәндә (әлеге Критерийләрнең 5 таблицасында күрсәтелгән төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларыннан тыш) 1 таблица нигезендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре һәм 2 һәм 3 таблицалар нигезендә куркыныч критерийләре кулланыла.

1 таблица

Башкарыла торган эшчәнлек төрләре

| Башкарыла торган эшчәнлек төрләре | Баллар |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Хайваннарны карап тоту (шул исәптән вакытлыча) (инсетариумдагы агулы булмаган бөҗәкләр, аквариум балыклары һәм судагы умыртка баганасызлар, террариумдагы агулы булмаган җир-су хайваннары, рептилияләрдән тыш), хайваннар үрчетү (инсетариумдагы агулы булмаган бөҗәкләр, аквариум балыклары һәм судагы умыртка баганасызлар, террариумдагы агулы булмаган җир-су хайваннары, рептилияләрдән тыш), хайваннарны сату, хайваннарны чалу, хайваннарны күчерү, хайваннарны куу; туплау, саклау | 5 |
| Биологик калдыкларны һәм терлекчелек калдыкларын күчерү (урынын алыштыру), зарарсызландыру, биологик калдыкларны һәм терлекчелек калдыкларын утильләштерү һәм юк итү; хайваннарны дәвалау; тикшерүдәге товрлар һөнәрчелеге (аулау). Хайваннардан эшләнгән зарарсызландырылмаган техник чималны әзерләү, саклау, күчерү һәм сату. | |
| Таможня берлеге комиссиясенең «Евразия икътисад берлегендә ветеринария-санитария чараларын куллану турында» 2010 ел, 18 июнь, 317 нче карары белән расланган Ветеринария контроле (күзәтчелеге) ясалырга тиешле товарларның бердәм исемлегенә | 4 |

| 1 | 2 |
|---|---|
| кертелгән товарларны (алга таба – контрольдәге товарлар) җитештерү, эшкәртү, түбәндәгеләрдән тыш:<br>бал һәм умартачылык продуктлары,<br>контрольдәге товарлар, әгәр аларны эшкәртә торган объект термик эшкәртү үткән хайваннардан эшләнгән продукция чыгармаса.<br>Сыйфатсыз һәм куркыныч дип танылган контрольдәге товарларны җыю, саклау, күчерү (урынын алыштыру), зарарсызландыру, утильләштерү һәм юк итү | |
| Контрольдәге товарларны саклау һәм сату, түбәндәгеләрне саклау һәм сатудан тыш:<br>бал һәм умартачылык продуктлары,<br>контрольдәге товарлар, хайваннардан эшләнгән бары тик эшкәртелгән чималдан алынган контрольдәге товарлар.<br>Контрольдәге товарларны күчерү (урынын алыштыру), термик эшкәртү үткән хайваннардан эшләнгән продукцияне күчерүдән (урынын алыштырудан) тыш.<br>Контрольдәге товарларны зарарсызландыру, утильләштерү һәм юк итү, сыйфатсыз һәм куркыныч дип танылган контрольдәге товарлардан тыш | 3 |
| Терлек азыгы һәм терлек азыгы өстәмәләре җитештерү | 2 |
| Инсетариумдагы агулы булмаган бөҗәкләр, аквариум балыклары һәм судагы умыртка баганасызлар, террариумдагы агулы булмаган җир-су хайваннары, рептилияләне карап тоту, үрчетү, үстерү, сату.<br>Түбәндәгеләрне җитештерү, эшкәртү, саклау һәм сату:<br>бал һәм умартачылык продуктлары,<br>термик эшкәртү үткән контрольдәге товарлар.<br>Термик эшкәртү үткән хайваннардан эшләнгән продукцияне күчерү (урынын алыштыру) | 1 |

«Гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төре» критериесе буенча эшчәнлекнең ике яки күбрәк төрен гамәлгә ашырганда гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләренең иң югары баллы исәпкә алына.

2 таблица

Куркыныч критерийләре

| Зоосанитар статус (дуңгызчылык хуҗалыкларына, шулай ук дуңгыз суюны, дуңгызчылык продукциясен эшкәртү һәм саклауны оештыруны гамәлгә ашыручы оешмаларга тарала), компартмент дәрәҗәсе* | Баллар |
|---|---|

| | |
|---|---|
| I компартмент | 5 |
| II компартмент | 4 |
| III компартмент | 3 |
| IV компартмент | 2 |

---

* Дуңгызчылык хуҗалыкларының, шулай ук дуңгыз суюны, дуңгызчылык продукциясен эшкәртү һәм саклауны гамәлгә ашыручы оешмаларның зоосанитар статусы Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Дуңгызчылык хуҗалыкларының, шулай ук дуңгыз суюны, дуңгызчылык продукциясен эшкәртү һәм саклауны гамәлгә ашыручы оешмаларның зоосанитар статусын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 ел, 23 июль, 258 нче боерыгы нигезендә билгеләнә.

3 таблица

Хайваннарның йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары барлыкка килүнең (теркәлүнең) соңгы очрагыннан соң вакыт чоры

| Җитештерү объекты территориясендә чикләүче чаралар (карантин) урнаштыру мөмкин булган хайваннарның йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары барлыкка килүнең (теркәлүнең) соңгы очрагыннан соң вакыт чоры (хайваннарны карап тоту, үрчетү һәм үстерү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы физик һәм юридик затларга тарала) | Баллар |
|---|---|
| 1 елдан ким | 5 |
| 1 елдан артык, әмма 2 елдан ким | 4 |
| 2 елдан артык, әмма 3 елдан ким | 3 |
| 3 елдан артык, әмма 4 елдан ким | 2 |
| 4 елдан артык, әмма 5 елдан ким | 1 |
| Хайваннарның йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары теркәлмәгән | 0 |

3. Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү куркынычның билгеләнгән категорияләре буенча 1 таблица буенча баллар суммасын 2 һәм 3 таблицалар буенча билгеләнгән балларга кушу һәм килеп чыккан сумманы 4 таблица нигезендә критерийләрне исәпләү өчен файдаланыла торганнар санына бүлү юлы белән исәпләнә.

монда:

Σ – балларның уртача арифметик суммасы;

$К_v$ – 1 таблица нигезендә бирелгән баллар суммасы;

$К_n$ – 2 таблица нигезендә бирелгән балл;

$К_m$ – 3 таблица нигезендә бирелгән балл;

p – 1 – 3 таблицалар нигезендә баллары 0 гә тигез булмаган критерийләр саны.

4 таблица

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларын куркынычның билгеле бер категориясенә кертү

| Куркыныч категориясе | Балларның уртача арифметик суммалары |
|---|---|
| Куркынычның гаять югары категориясе | 4,50 дән 5,00 гә кадәр |
| Куркынычның югары категориясе | 3,91 дән 4,49 га кадәр |
| Куркынычның урта категориясе | 2,50 дән 3,90 га кадәр |
| Куркынычның уртача категориясе | 1,50 дән 2,49 га кадәр |
| Куркынычның түбән категориясе | 1,49 дан һәм түбәнрәк |

4. Хайваннарның йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары буенча чикләүче чаралар (карантин)* гамәлдә булган һәм чит ил дәүләтләреннән хайваннарны алып кергәндә аларны карантинлау гамәлгә ашырылган төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелегенең аерым объектларын куркыныч категориясенә кертү 5 таблица нигезендә гамәлгә ашырыла.

5 таблица

Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектларының куркыныч категорияләре

| Төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектлары | Куркыныч категориясе |
|---|---|
| Хайваннарның йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары буенча чикләүче чаралар (карантин)* гамәлдә булган объектлар | гаять югары куркыныч |
| Чит ил дәүләтләреннән хайваннарны алып кергәндә карантинлау гамәлгә ашырылган объектлар | югары куркыныч |

* Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2011 ел, 19 декабрь, 476 нче боерыгы белән расланган Хайваннарның чикләүче чаралар (карантин) билгеләү мөмкинлеге булган йогышлы, шул исәптән аеруча куркыныч авырулары исемлеге.

## III. Мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге критерийләре

1. Объектны куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул иткән көнгә кадәрге ике ел эчендә законлы көченә кергән Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 10.6 – 10.8 статьяларында, 14.43 статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә, 14.44 – 14.46 статьяларда, 14.46.2 статьяның 1 – 4 өлешләрендә, 19.5 статьяның 8 һәм 8.1 өлешләрендә, бүтән статьяларда каралган административ хокук бозулар өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки хезмәткәрләренә, шәхси эшмәкәргә, аның хезмәткәрләренә административ җәза билгеләп, административ җаваплылыкка тарту турында карар булганда, алар буенча эшләрне карап тикшерү һәм (яки) беркетмәләр төзү Идарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан

гамәлгә ашырылганда әлеге Критерийләрнең II бүлеге нигезендә югары, урта, уртача һәм түбән куркыныч категорияләренә кертелгән төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектлары куркынычның югарырак категориясенә (бер позициягә) кертелергә тиеш.

2. Объектны куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул иткән көнгә кадәрге ике ел эчендә әлеге бүлекнең 1 пунктында күрсәтелгән административ хокук бозулар өчен юридик затка, аның вазыйфаи затларына яки хезмәткәрләренә, шәхси эшмәкәргә, аның хезмәткәрләренә административ җәза билгеләп административ җаваплылыкка тарту турында карар булмаганда югары, урта, уртача һәм түбән куркыныч категорияләренә кертелгән төбәк дәүләт ветеринария күзәтчелеге объектлары куркынычның түбәнрәк категориясенә (бер позициягә) кертелергә тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин